Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советының кырык сигезенче утырышы

Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

23 июль, 2025 ел № 126

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советы түбәндәге карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советына исәпкә алу вәкаләтләрен кабул итү, шулай ук муниципаль мөлкәт һәм авыл җирлегенең җир ресурслары белән эш итү турындагы тәкъдимне карарга тәкъдим итәргә.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы А.Р.Сәйфетдинов